РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУСЛЮМОВСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
ТОЙГИЛЬДИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТОЙГЕЛДЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423974, РТ. Муслюмовский район, с.Тойгильдино, ул.Центральная д.4/2,
Toy.Mus@tatar.ru тел. (8-85556) 3-46-31
ИНН 1629003872, КПП 162901001, ОГРН 1061687001188, ОКАТО 92242875000.

*Тойгелде авылы* *«03» февраль 2020 ел*

**Карар № 3**

**«Тойгелде авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм Тойгелде авыл җирлегенең салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау турында» 2019 елның 13 декабрендәге 17 номерлы Тойгелде авыл җирлеге карарына үзгәрешләр кертү хакында**

РФ Бюджет кодексының 174.3 статьясы, «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә гомуми таләпләр турында» РФ Хөкүмәтенең 2019 елның 22 июнендәге 796 номерлы карары нигезендә, Мөслим муниципаль районының Тойгелде авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Тойгелде авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм Тойгелде авыл җирлегенең салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау турында» 2019 елның 13 декабрендәге 17 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Әлеге карарга 1 нче кушымтада расланган Тойгелде авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм Тойгелде авыл җирлегенең салым чыгымнарын бәяләү тәртибенең 19 пунктының б) пунктчасындагы 2 абзацын түбәндәге формула белән тулыландырырга:

$$E = \sum_{i=1}^{5}\sum_{j=1}^{m_i} \frac{N_{ij} - B_{oj} \times \left(1 + g_i\right)}{\left(1 + r\right)^i},$$

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында (http://muslumovo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Тойгелде авыл җирлеге территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карар закон белән билгеләнгән срокта үз көченә керә.

Тойгелде авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе Фәйзуллина Э.Н.